МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.06.2021 Казан ш. № под-868/21

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 25 июлендәге 4231/14 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, квалификация категориясе билгеләү максатларында, Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, квалификация категориясе билгеләү максатларында, Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның  педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең  административ регламентын раслау турында» 2014 елның 25 июлендәге 4231/14 номерлы боерыгы (2016 елның 22 июнендәге под-1244/16 номерлы, 2019 елның 26 февралендәге под-303/19 номерлы, 2020 елның 12 ноябрендәге под-1184/20 номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, квалификация категориясе билгеләү максатларында, Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең  административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.3 пунктның 1.3.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mon.tatar.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru/) (алга таба – Республика порталы);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

3) Министрлыкка телдән (шәхсән яки телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ формасында да) мөрәҗәгать иткәндә;

5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (http://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры)»;

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.3.7 пунктчасын өстәргә: «Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын да күрсәтеп) Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылган.

Административ регламент тексты Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылырга тиеш.»;

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«ИАБС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы.

Мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар (мөрәҗәгать итүче гражданнар һәм башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары) өчен дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системала-

рында булган мәгълүматтан санкцияле рәвештә файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы;»;

2 бүлектә:

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки кәгазь документ нөсхәсе рәвешендә алырга хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Министрлык вазыйфаи затының (яисә Министрлыкның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза һәм теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Республика порталы аша электрон рәвештә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гариза белән кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гаризаны гади электрон имза белән имзалый. Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.»;

2.7 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта.

2. Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру.

3. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр категориясенә керми торган затларның гариза белән мөрәҗәгать итүе.»;

2.16 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

д) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хез-

мәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Республика порталы аша җибәрелгән гаризада бу хакта күрсәтелгән булса, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Республика порталы аша электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында бирелә.

Гариза электрон рәвештә формалаштырылганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә: хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларны саклау мөмкинлеге; гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару мөмкинлеге; файдаланучы ихтыярына карап, теләсә кайсы вакытта электрон формага элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау, шул исәптән электрон формага ялгыш кертү һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы килеп туганда да; Бердәм порталда урнаштырылган белешмәләрне һәм Республика порталында урнаштырылган белешмәләрне кулланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон форма кырларына белешмәләр кертелә башлаганчыга кадәр Бердәм порталда булмаган белешмәләргә кагылган өлештә кырларны тутыру; элегрәк кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, электрон форма тутыруның теләсә кайсы этапларына кире әйләнеп кайту мөмкинлеге; мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы элегрәк бирелгән гаризаларны карый алу мөмкинлеге.

Гаризаны җибәргән вакытта, мөрәҗәгать итүченең шәхесе исәпкә алу язуын активлаштырганда билгеләнгән булу шарты белән, гади электрон имза кулланыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язылу) Республика порталы аша гамәлгә ашырыла.

Билгеле бер датага язылу вакыты әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресы (ихтыярына карап);

теләнгән кабул итү датасы һәм вакыты.

Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.»;

3 нче бүлектә:

3.3.1 пунктчаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүче Министрлыкка, турыдан-туры аттестацияләү комиссиясенә квалификация категориясен билгеләү максатларында аттестация үткәрү турында гариза тапшыра, яисә аттестацияләү комиссиясе адресына «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» комплекслы проектын кулланып, электрон документ формасында яисә «Татарстан Республикасында Электрон мәгариф» мәгълүмат системасында электрон рәвештә электрон тапшыру турында белдереп, хат юллый.

Гаризаны электрон формада җибәргән очракта сорала торган документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре кушыла, гариза почтадан җибәрелгән, – мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар.

Гаризаны Республика порталы аша электрон формада тапшырган очракта, мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында авторизация уза; Республика Порталында электрон гариза формасын ача; дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра; электрон гариза формасына (кирәк булган очракта) электрон формада документлар яки документларның электрон рәвешләрен беркетә; электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышып чыгу һәм ризалашу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге билгели); хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге билгели); тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса); электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган гариза һәм документлар.»;

5 бүлекнең 5.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.».

2. Кадрлар сәясәте бүлеге җитәкчесенә (Л.С.Әмирова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары А.И.Поминовны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин